Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы торак пунктында үткән гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

2021 елның 26 ноябре №2

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлеге составына керүче Яңа Арыш авылы торак пунктында үткән гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең Яңа Арыш авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;
2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:
   - Яңа Арыш авылында юллар ремонты өчен вакланган таш сатып алу;
   - транспорт хезмәтләре өчен түләү;
   - кышкы чорда Яңа Арыш авылында юлларны карап тору;
   - МТЗ-82 тракторына бульдозер сатып алу;
   - МТЗ-82 тракторы өчен чапкыч сатып алу;
   - скважинаны рәсмиләштерү өчен түләү;
3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Яңа Арыш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яңа Арыш авылы, Мәктәп урамы, 30 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Зарипов Х.С.

Яңа Арыш авыл җирлеге башлыгы Зарипов Х.С.